РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

30.03.2021 г. Олы Кайбыч ав. № 06

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә кешеләр күпләп була торган урыннарны категорияләү һәм паспортлаштыру буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр кертү турында**

Милли террорчылыкка каршы комитетның 2017 елның 08 августындагы 11/П/2-1427 ДСП карарын үтәү йөзеннән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләр күпләп була торган урыннарның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы якланууына таләпләрен һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) иминлеге паспортлары рәвешләрен раслау турында» 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карары нигезендә һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә кешеләр күпләп була торган урыннарны категорияләү һәм паспортлаштыру буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр кертергә һәм кушымтада каралганча расларга.
2. Комиссия рәисенә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә кешеләр күпләп була торган урыннарны категорияләү һәм паспортлаштыру буенча тиешле Исемлеккә кертелгән комиссия эшен дәвам итәргә.
3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**А.И.Рәхмәтуллин**

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Башлыгының 2021е. 30 мартындагы
06 номерлы боерыгына
кушымта

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә кешеләр күпләп була торган урыннарны категорияләү һәм паспортлаштыру буенча ведомствоара комиссия**
**СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| **Комиссия рәисе:**<br>Макаров А.Н. | Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе |
| **Комиссия рәисе урынбасары**<br>Сәгъдиев А.Р. | Яшел Үзән шәһәрендә РФ Федераль куркынычсызлык хезмәтенең ТР буенча идарәсе бүлекчәсе хезмәткәре (килешү буенча) |
| ***Комиссия әгъзалары***<br>Мингазов Г.Ф. | Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Кайбыч районы буенча бүлеге башлыгы урынбасары |
| Җиһаншин А.Д. | «ТР буенча Россия Милли гвардиясе гаскәре» ведомстводан тыш сак идарәсе Федераль дәүләт казна учреждениесенең буа район-филиалы ведомстводан тыш сак бүлегенең үзәкләштерелгән сак пункты башлыгы (килешү буенча) |
| Вәлиев И.И. | Күзәтү идарәсе һәм профилактика эше Россия баш идарәсенең ТР буенча Кайбыч һәм Апас муниципаль районнары буенча районара күзәтү эшчәнлеге бүлеге һәм Россия ГТХМ Татарстан буенча Баш идарәсе районара бүлеге башлыгы |
| Сөнгатуллин Р.Р. | Кешеләр күпләп була торган урыннар милекчесе (хокук иясе) |